## 1. Тигәнәкле су буе

Яңгырый шау –гөр җыен,
Качышлы безнең уен.
Бүген сүз куешкан урын –
Тигәнәкле су буе.
Кушымта: Су буенда тигәнәк,
Тигәнәктә – күбәләк.
Күбәләкне очырмакчы
Яңгыр, вак-вак сибәләп.
Бәйләнчек лә тигәнәк:
Тиктомалдан бәйләнә.
Балаккамы, күлмәккәме,
Ябышмакчы хәйләләп.
Кушымта.
Тимәс, дидек,тигәнәк
Кереп киттек үрмәләп.
Атлап түгел, очып чыктык -
Дүңгәл – дүңгәл - дүңгәләк.
Кушымта.
Без тамырлы, без милләт,
Түгел дүңгәл – дүңгәләк,
Күбәләк, дип, күңелләргә
Ябышмасын тигәнәк.